Сөй гомереңне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №64 (7237) | 4 июнь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## КӨНГӘ—16,5 КИЛОГРАММ

«Россия» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасы хезмәтчәннәре ел башыннан уңышлы старт алдылар. Алар кабул итеп алынган йөкләмәләрне һәм еллык планнарны арттырып үтәү өчен зур тырышлык куеп эшлиләр.

Сыер савучылар арасында Анна Портнова лидерлыкны үз кулында тота. Тәҗрибәле савымчы бүгенге көндә һәр сыердан уртача 16,5 килограмм сөт сава. Лидия Яллина, Валентина Наумованың да күрсәткечләре начар түгел. Алар ел башыннан һәр сыердан 1536—1455 килограмм сөт саудылар.

Ферма буенча исә көнлек савым —13 килограмм.

## КПСС райкомы бюросында һәм район башлангыч партия оешмалары секретарьлары киңәшмәсенә катнашучылар

# МӨРӘҖӘГАТЕ

КПСС райкомы бюросы һәм район партия оешмасының башлангыч партия оешмалары секретарьлары Татарстан ССР-ның беренче Президентын сайлау буенча үз позицияләрен барлык коммунистларга, районның барлык халкына җиткерүне кирәк дип саныйлар.

Республикабызда политик һәм экономик яктан хәл катлаулы. Элеккеге вертикаль структуралар инде эшләмиләр, ә горизонталь мөнәсәбәтләр авырлык белән һәм еш кына стихияле җайга салына.

Үзебезнең интересларыбызны гомумсоюз дәрәҗәсендә реализацияләүгә, властьның республика органнары вәкаләтен күтәрүгә ирешү өчен республика халык сайлаган кешеләргә тапшырырга һәм тиешле вәкаләтләр халык исеменнән билгеләнергә тиеш. Татарстан республикасы Президенты постына ТССР Югары Советы рәисе Минтимер Шәриф улы Шәймиев кандидатурасы күрсәтелде. Ул 20 дән артык коллективта якланды һәм аны яклап 200 меңнән күбрәк имза җыелды. Болар барысы да М. Ш. Шәймиевка республиканың күпчелек халкы югары ышаныч белдерүе турындагы дәлилләр.

М. Ш. Шәймиев—коммунист, КПСС Үзәк Комитеты, КПСС рескомы әгъзасы. Ул партиябез политикасы һәм аны тормышка ашыру турында сүз барганда һәрвакыт нык һәм эзлекле линияне алып бара.

Менә шулардан чыгып, КПСС райкомы бюросы һәм партоешма секретарьлары, район партия оешмаларының барлык комунистларына һәм район сайлаучыларына, ТССР Президенты постына лаеклы, тәҗрибәле, компетентлы, Татарстан суверенитетын эзлекле яклаучы М. Ш. Шәймиев кандидатурасын якларга һәм 1991 елның 12 июнендә тавышларыбызны аңа бирергә чакырып мөрәҗәгать итәләр.

**Мөрәҗәгать 1991 елның 31 маенда кабул ителде.**



**Чирек гасыр гомере җиргә хезмәттә үтте аның. Җир сулышын тыңлап, ул муллыктан балкыганда сөенеп, ул уңышсыз сыкраганда көенеп яшәү Җәүдәт Касыймовичның төп тормыш мәгънәсен тәшкил итте. Үзенә беркетелгән К-700 тракторы белән кышын-көзен бер дә эштән бушамый ул. Инде яз җитте исә, ул икеләтә эшле ритмга күчә: К-700 ен куя да ДТ-75 кә утырып, басуларга юнәлә, икмәк өчен көрәшүче игенчеләр сафына кушыла.**

**Быел да ул бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар чәчүдә эшләде. «Татарстан» колхозында чәчү ике сменада оештырылды. Җәүдәт Касыймович кебек тәҗрибәле механизаторларга күбрәк төнге сменада эшләргә туры килде.**

**Гаҗәеп сабырлык, һәр эшне җиренә җиткереп үтәү гадәте аңа быел да уңыш китерде.**

**Рәсемдә: «Татарстан» колхозы механизаторы Җ. К. Миндубаев.**

## Кем ота, кем оттыра

27 майда Ульянов исемендәге колхоз заводка сөт алып килгән иде. Документ буенча сөтнең майлылыгы 3,6 процент дип күрсәтелгән, ә заводта кабат тикшерү аның 4,1 булуын күрсәтте. Шул сәбәп аркасында колхоз тапшырган сөтнең күләме 100 килограммга арттырып язылды.

**29 майда да шундый ук хәл кабатлана. Накладнойда күрсәтелгән 3,6 урынына чынлыкта аның майлылыгы 4,3 процент икәнлеге, ягъни күрсәтелгәннән 0,7 процентка күбрәк булып чыга һәм шуның бәрабәренә сөт тә 252 килограммга арттырыла.**

**Мондый мисалларны тагын да китерергә мөмкин. Шул ук көнне «Мамык» совхозының II бригадасыннан килгән сөтнең дә күрсәтелгән майлылыгы 4,0 процент урынына 4,5 процент икәнлеге ачыклана.**

**27 нче майда «Татарстан», 14 майда «Комбайн» колхозларыннан килгән сөтнең дә майлылыгы дөрес билгеләнмәгән. Беренчесендә ул 0,3 процентка, икенчесендә 0,4 процентка кимсетеп күрсәтелгән.**

**Бу фактларның барысы да урыннарда контрольнең тиешле дәрәҗәдә булмавын, моңа белгечләрнең җавапсыз каравын күрсәтә.**

**Моны дәлилләп тагын «Москва», «Заветы Ильича» кебек колхозларның сөтне берничә ункөнлек буенча II, III сорт белән тапшыруы һәм бу хәлнең беркемне дә борчымавы гаҗәпләндерә.**

**Ә 28 майда XXI партсъезд исемендәге колхозда шәхси хуҗалыклардан җыелган сөтне колхозныкына кушалар. Нәтиҗәдә 880 килограмм сөт әчегән булып чыга. Сөт заводының сөтне төнлә дә кабул итүен күп хуҗалык җитәкчеләре исәпкә алмыйлар, шулай булмаганда «Алга» колхозы һәм «Мамык» совхозы кебек хуҗалыклар суыту җайланмалары сафтан чыгуын сәбәп итеп 1500, 1720 килограмм сөтнең кире кайтарылуына юл куймаслар иде.**

**Соңгысын, хуҗасызлык дип атыйк та ди, анысы бездә, шөкер, «чәчәк ата». Ә инде алда китерелгән фактны ничек бәяләргә?**

## „Кечкенә Алиягә булышыгыз“

### (шәфкатьлелек хәрәкәте юл ярә)

Нәни Алия Садретдинованың авыруы, аңа бөтен халык ярдәме кирәклеге турында иң беренче булып без—редакция хезмәткәрләре белдек. Аның язмышы безнең һәрберебезне чиксез тетрәндерде. Шуңа да гаиләгә ярдәм йөзеннән акча җыярга булдык. «Дуслык» район газетасының кечкенә генә коллективы махсус счетка 208 сум акча кертте. Ил төкерсә, күл була, дибит халык. Мондый шәфкатьлелекне һәр коллектив эшләр дип өметләнәбез.

Безнең кечкенә генә өлешебез Алиянең тормышын саклап калуга булышсын иде. Терелүеңне телибез, Алия!

## КЫШКА ХӘЗЕРЛЕК

Синдряков исемендәге колхоз идарәсенең чираттагы утырышында терлекчелек биналарын кышкы чорга әзерләү буенча махсус звено оештыру турында сүз булган иде. Инде җәмәгать маллары җәйләүгә чыгарылды, биналар бушады. Хәзер моңа әзерлек эшләре бара: төзү материаллары туплана, фермаларга капиталь ремонт үткәрү эшенә дә керешеп киләләр.

## Уртак бәйрәм

Салдакай авылында милли бәйрәм—сабантуй икенче ел үткәрелә. Аның программасына атлар чабышы, капчыклар белән сугышу, гер күтәрү, татарча көрәш кебек ярышлар кертелгән иде. Бәйрәмдә язгы чәчүдә механизаторлар эшенә йомгак та ясалды. Бу чәчү родиналылар өчен бик катлаулы шартларда узды, колхозның баш агрономы В. Сандрюхин шул шартларда намуслы хезмәт куйган алдынгылар исемен горурланып атады.

Ә аннан халыкны кызыксындырган ярышлар башланды. Ат узышына өч хуҗалыктан атлар килгән иде. Атлар чабышында Э. Васюткин нярләгән «Пират», Р. Мөфтихановның «Вайгул»ы беренче ике урынны алдылар. Өченче булып В. Сандимировның «Абрегы» килде. Алар һәммәсе—«Родина» колхозыннан.

Һәр төр ярыш үз җиңүчеләрен атады. Капчыклар белән сугышуда М. Сәләхетдинов һәм А. Васюткин, капчык киеп йөгерүдә О. Миронов алга чыкты. 16 килограмм герны 27 тапкыр чөеп гер күтәрүдә В. Сандимиров җиңде.

Шулай итеп, сабантуй үзенең иң төп ярышы—татарча көрәшкә җитте. Быел да анда беренче урынны Гамирулла Хәмидуллин алды. Икенче урында Илдар Хәмидуллин, өченче урында Муса Җәлил исемендәге колхоздан Госман Вәлиуллин булдылар.

Сабантуйда район потребительләр җәмгыятеннән күп санда кибетләр катнашты. Җәмәгать туклануы предприятиесе, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүнең район производство идарәсе вәкилләре үз продукцияләрен саттылар — боларның һәммәсеннән родиналылар бик канәгать калдылар. Акча-әйбер лотореясы да алар күңеленә хуш килде. Шулай милли бәйрәм милләтара бердәмлек, дуслыкны гәүдәләндереп, бик җанлы һәм күңелле үтте.

**С. НУРУЛЛИНА.**

## Беренче сабан туе

Нәрсәне генә беренче дип язмыйбыз без. Беренче чәчү язы, беренче колхоз рәисе, беренче сабан туе...Туган авылында сабан туе—ул бөтенләй үзгә икән бит.

Атлар чабышында таныш атлар, күңелгә якын җайдаклар артыннан йөгерәсе, ничек тә ярдәм итәсе килә...Бөтен авылдашларны җыйган кечкенә генә көрәш мәйданына чыгарга җилкенеп утырасың, эх... чыгып көрәшим әле дип җиңел генә урыныңнан кузгаласың. Бикколлылардан авылларында бу милли бәйрәмне картлар, ул чактагы бала-чагалар гына хәтерли. 34 нче елда соңгы сабан туе үткәрелә. Узган шимбәдә ул яңадан шул киселгән араны ялгады сыман. Әмма табигать җылы кояшын кызганды булса кирәк, шуңа карамастан, ул бикколлыларның кәефен боза алмады. Күнелгән төсмерләрен югалтмыйча, авыл артындагы яшел тугайда бәйрәмчә авазлар гөрләде.

Милли бәйрәмне авылның мулласы Исхак бабай Закиров ачып җибәрде. Шуны гына көткәндәй сабан туе уеннары башланды. Төп ярышларда җиңүчеләрне атап үтми мөмкин түгел. Атлар чабышында яшьләр арасыннан 6 нчы класс укучысы Марат Шәрәпов, олыраклардан «Таң» колхозы тракторчысы Раил Сөләйманов беренче килделәр.

Татарча көрәштә катнашучылар байтак иде. Соңгы—тәкә өчен көрәшкә колхозчылар гына кертелде. Алар—үз үлчәү категорияләре буенча җиңүчеләр, яшь тракторчы Радик Сәйфуллин һәм шоферлар Наил Кәримов һәм Ильяс Яруллин. Егетләр үзара көч сынашуны озакка сузмадылар. Тегү машинасы белән бергә тәкә дә Ильяска эләкте.

Сабан туеның буена җыр-музыка тавышы тынмады. Авылның атаклы җырчылары бәйрәм түрендә булдылар.

**Ф. ГАЛИМОВА.**

